| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«СУГУШЛИНСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«СУГЫШЛЫ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**Р Е Ш Е Н И Е** Сугышлы **КАРАР**

2018 елның 14 декабре №37

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Сугышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2015 елның 27 октябрендәге 37нче номерлы «Җир салымы турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында (2017 елның 30 маендагы 6 номерлы үзгәрешләр белән)

Россия Федерациясе Салым Кодексының 387 нче статьясының 2нче пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Сугышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы карар чыгарды:

1 Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Сугышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2015 елның 27 октябрендәге 37нче номерлы «Җир салымы турында» гы карарына (2017 елның 30 маендагы 6 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктка түбәндәге эчтәлекле 5нче абзац өстәргә::
«18 яшькә кадәрге дүрт һәм аннан да күбрәк балалары булган гражданнарның салым түләүдән азат итеп, ташлама бирергә.»,

түбәндәге эчтәлекле 5.1 пункт өстәргә:
«5.1 Салым түләүчеләр-салым ташламаларына, шул исәптән салымнар һәм җыемнар турындагы законнарда билгеләнгән салым тотып калынган салым рәвешендәге физик затлар салым ташламаларын бирү турындагы гаризаны үз теләге белән салым органына тапшыралар, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслаучы документларны тапшырырга хокуклы.

Салым ташламасын раслый торган документлар салым органында юк икән, шул исәптән салым түләүче тарафыннан салым ташламасы бирү турында салым түләүченең гаризасында күрсәтелгән мәгълүмат буенча салым органы салым ташламасына салым түләүченең хокукын раслый торган белешмәләрне салым

ташламасына салым түләүче органнарының, оешмаларның, вазыйфаи затларның әлеге мәгълүматлар булган органнарыннан соратып ала.

Салым органы салым ташламасына салым түләүченең хокукын раслый торган белешмәләрне тапшыру турында салым органы соратып алган зат аны алган көннән җиде көн эчендә яисә шул ук вакытта салым органына сорауның үтәлмәве сәбәпләре турында хәбәр итә.

Салым органы әлеге хәбәрне алган көннән соң өч көн эчендә салым түләүчегә салым ташламасына хокукын раслый торган белешмәләрне соратып алу турында һәм салым органына документларны раслый торган салым түләүче тарафыннан тапшыру кирәклеге турында хәбәр итәргә тиеш».

2. Әлеге карарны Сугышлы авылы, Центральная урамы, 27 йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка хәбәр итәргә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән бер ай узгач үз көченә керә һәм 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Сугышлы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге
Башлыгы, Совет рәисе Ф.К.Янгирова